РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН СОВЕТ
БИК-УТЕЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БИК-ҮТИ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

« 19 » августа 2020 года № 90-2

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы
Бик-Үти авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы
нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Буа муниципаль районы Бик-Үти авыл җирлеге Советы,

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Бик-Үти авыл җирлегендә 2018 елның 14 июлендә кабул ителгән 51-2 номерлы «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Бик-Үти авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау турында»гы Нигезләмәгә (2020 елның 12 маенда 84 номерлы карары редакциясендә) (алга таба – нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 33 статьясындагы 1 пунктының 2021 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдә булуын туктатып торырга;

1.2. Нигезләмәнең 36 статьясындагы 5 пунктының 1 абзацының гамәлдә булуын 2021 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

«Агымдагы финанс елының соңгы эш көненә кадәр кертеп, бюджет үтәлешенә казначылык хезмәтен башкаручы орган, билгеләнгән тәртиптә бюджетның бердәм счетында калган акчалар чикләрендә түләүгә санкцияләнгән бюджет йөкләмәләрен түләргә тиеш.»;

2. Әлеге карар рәсми бастырылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адрес буенча урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Буа муниципаль районы Бик-Үти
авыл җирлеге башлыгы,
Буа муниципаль районы
Бик-Үти авыл
җирлеге Советы рәисе Р.З. Залялетдинов